Бүгенге санда:



Быел 8759 нурлатлы диспансерлаштыру узарга тиеш. 3 бит


1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 8 апрель 2015 ел

№ 25 (10554)


**9 апрельгә һава торышы:** болытлы һава, яңгыр, үзгәрүчән юнәлешле җил 4-5 м/с; температура көндез +5°С, төнлә +2°С

### Җиңү календаре

**31**

**БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ – 9 МАЙГА КАДӘР ШУЛКАДӘР ВАКЫТ КАЛДЫ**

*1945 елның 6-9 апрелендә Кенигсберг операциясе үтә. Аның барышында немецларның Көнчыгыш Пруссия төркеменең төп көчләре Советлар Союзы маршалы Александр Василевский командалыгындагы Знче Белоруссия фронты гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителә.*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### МАЙГА КАДӘР ДӘВАМ ИТӘЧӘК

Узган атна азагында районның авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре һәм авыл җирлекләре Казанның агросәнәгать паркында чираттагы ярминкәдә катнаштылар. Бу юлы башкала халкы нурлатлылар тәкъдим иткән сөт һәм сөт ризыкларын, итләрне аеруча яратып алган. Казанда ярминкәләр исә май аена кадәр дәвам итәчәк, нурлатлылар анда ике атнага бер тапкыр катнаша.

### ӘЗЕРЛЕКНЕ КОМИССИЯ ТИКШЕРӘ

Иртәгә район хуҗалыкларының язгы кыр эшләренә әзерлеген республика комиссиясе тикшерәчәк. Тикшерү республикада чәчүгә әзерлек буенча авыл хуҗалыгы предприятиеләре арасында игълан ителгән конкурс кысаларында үтә. Комиссия техниканың торышы белән бергә хезмәтне саклау һәм игенчелек буенча чараларның тиешенчә үтәлешенә дә зур игътибар бирәчәк.

### ЮБИЛЕЙГА БАГЫШЛАНДЫ

Кичә районның барлык мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган "Бу көннәрнең даны онытылмас" дип аталга район конкурсында катнашты. Чыгышлар район мәдәният йортында "Вокал", "Вокаль ансамбльләр", "Сәнгатьле сөйләм", "Театраль күренеш" номинацияләре буенча әзерләнгән иде.

# Алар һаман алгы сызыкта



Автор фотосы

ХӘЛИУЛЛА КӘЛИМУЛЛИН БҮГЕН ДӘ КЫЗЫКЛЫ ӘҢГӘМӘДӘШ ӘЛЕ.

**Алар Бөек Ватан сугышында да, соңрак тыныч хезмәттә дә алгы сызыкта булган. Бүгенге көндә дә кадер һәм кайгырту тоеп, хөрмәтле картлык кичерәләр. Сүзебез Нурлатның Бөек Ватан сугышы ветераннары Хәлиулла Кәлимуллин, Ирек Алишев, Габделхәй Яһудин һәм аның тормыш иптәше, тыл хезмәтчәне Сәрвәрия ханым турында.**

Бөек Җиңүнең 70 еллыгына әзерләнгән бүләк җыелмаларын район башлыгы Равил Кузюров аларның өйләренә барып тапшырды. Яшьләре 90да булса да, һәркайсы район башлыгын ишектән үк үзләре каршы алырга ашыкты. 1942нче елда сугышка алынып, туган якларына бары тик 1950 елда гына әйләнеп кайткан Хәлиулла Кәлимуллович белән Равил Әфраимович хәрбиләрчә күреште. Ә ветеранның хәтер йомгагы янә сугыш елларына әйләнеп кайтты. Өйрәнү отряды составында Төньяк флотын ныгытулары, артиллерист-минометчы булып Онега күленең гамәлдәге хәрби флотилиясе составында мина катерларында сугышуы, Петрозаводск, Онега күлен азат итүләре, Хельсенкига кадәр барып җитүләре хакында сәгатьләп сөйли ала ул. Тыныч тормышта колхоз рәисе, Нурлат элеваторы җитәкчесе булып эшләгән ветеран I дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм башка дәрәҗәле бүләкләр белән бүләкләнгән. Бүгенге көндә кече улы Ринат һәм килене Гүзәлия гаиләсендә яши, ил-көн вакыйгаларыннан хәбәрдар, кызыклы әңгәмәдәш тә әле.

Сугыш ветераны Габделхәй Яһудин белән җәмәгате Сәрвәрия ханым да район башлыгын көтелгән кунак итеп кабул иттеләр. Озак еллар буена авыл хуҗалыгында хезмәт куйган, колхоз рәисе булып эшләп, ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исеменә лаек булган Габделхәй Афзалович язгы чәчүгә әзерлекнең барышы белән кызыксынып, үзе эшләгән вакытларны искә төшерде, шунда ук төпле киңәшләрен бирергә ашыкты. Сугыштан яраланып кайтып, тыныч тормышта дәрәҗәле хезмәт юлы узган, тормыш иптәше белән илгә лаеклы балалар тәрбияләп үстергән Габделхәй ага хәзер район чараларының иң хөрмәтле кунакларыннан, үзе дә актив тормыш рәвеше алып бара. Әнә, Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан юбилей медален дә башка кардәшләре белән Мәдәният сараенда үткән чараларда кабул итеп алды. Ә менә гомере буена балаларга белем биргән Сәрвәрия ханымның күкрәгенә юбилей медален район башлыгы шул көнне такты, Яһудиннарга исәнлек-саулык теләде.

Тагы бер тынгысыз ветеран – Ирек Исхак улы Алишев та кунакларны ачык йөз белән каршы алды. Җәйгә 90ны тутырса да, тик тора белми ветеран - тәрәзә төпләре тулы яшелчә үсентеләре, өстәлдә – үзе җәйдән тозлап калган помидор, соклар, ә киштәләрдә – гармуннары хуҗаларының вакыты тигәнне көтеп утыра. Әнә шулай, ветераннар елларга бирешми һәм күңелләреннән яшәү дәрте озак вакытлар китми яшәсен иде әле.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

АКТУАЛЬ

# Тычкан бизгәге баш калкыта

**Быелның I кварталында районда бөер синдромлы геморрагик бизгәкнең (ГЛПС) 9 очрагы теркәлгән. Узган елның шул чорында исә Нурлатта мондый очрак бөтенләй булмаган.**

Кешеләрнең елның теләсә кайсы вакытында ГЛПС эләктерү куркынычы бар. Быелгы 9 очракның 8е гыйнварга, 1се февральгә туры килә. Авыручыларның барысы да 21-53 яшьлек хезмәткә сәләтле кешеләр.

– Авыручылар арасында шәһәрлеләр күбрәк – 7әү, – диде ТР гигиена һәм эпидемиология үзәгенең Нурлат районындагы табиб-эпедимиологы Владимир Александров. – Алар чирне урманда яки басуда эләктергәннәр. Авыручыларның хезмәт урыннары авыл җирлекләренә, урман-кырларга чыгып эшләү белән бәйле, нәкъ әнә шул җирләрдә кимерүчеләр яисә алардан калган продуктлар белән контактка керү ихтималы зуррак та. Авыл кешеләре кимерүчеләр белән көнкүреш шартларындагы контакттан, мал-туар караганда, азык әзерләгәндә, абзарларда чакта авыру эләктерәләр.

(Дәвамы 2нче биттә)




**"ДУСЛЫК"КА ЯЗЫЛУ БАРА**

*"ДУСЛЫК" ("ДРУЖБА", "ТУСЛАХ") район газетасына 2015 елның II яртыеллыгына язылу бара. 6 айга язылу – 528 сум, альтернатив әбунә – 330 сум.*

Сезне почтада һәм редакциянең реклама бүлегендә көтәләр.

# ВӘЗГЫЯТЬ

МӘГАРИФ

## УКЫТУЧЫЛАРНЫ УКЫТТЫЛАР

Районның 100 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәре ике көнлек семинар-уку үтте. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә ФГОС нигезендә билингваль укыту темасына багышланган укуларда "Әкият" балалар бакчасы тәрбиячесе Рәсимә Рәхимова, "Чишмәкәй"дән Рәслимә Мостафина ачык дәресләр күрсәттеләр. Шунысын әйтергә кирәк, шәһәрнең "Әкият" һәм "Камыр батыр" балалар бакчалары "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" республика грантына ия инде.

## ЯШЬ ЭНЕРГЕТИКЛАР БҮЛӘКЛӘНДЕ

"Энергонәтиҗәле энергия саклау" фәнни-техник проектларның II республика яшьләр конкурсыннан Балалар иҗаты үзәгендә шөгыльләнүче Руслан Мостафин, Булат Фәтхетдинов һәм Айнур Төхфәтуллин призлы урыннар яулап кайттылар. "Энергонәтиҗәле яшәү рәвеше" номинациясендә яшь нурлатлылар диплом һәм акчалата приз белән билгеләп үтелгәннәр.

Зилия ӘКСАНОВА

## ТАТАРЧА СӨЙЛӘШИК!

**Без, Нурлат шәһәре 9 нчы урта гомуми белем мәктәбе укучылары һәм укытучылары, " Мин татарча сөйләшәм" республика конкурс-акциясендә катнаштык.**

Акция кысаларында мәктәптә, "Шифа" сәүдә үзәгендә, Нурлат бораулау эшләре предприятиесендә һәм шәһәрнең төрле көнкүреш хезмәте күрсәтә торган урыннарында очрашулар, мастер-класслар үткәрдек. Шәһәребез халкын күбрәк татар телендә сөйләшергә, аралашырга өндәп, акциянең "Мин татарча сөйләшәм" логотибын һәм "Твои 150 слов на татарском" дигән сүзлек-буклетлар тараттык. Бу чаралар "Мин татарча сөйләшәм, әйдә, син дә татарча сөйләш!" девизы астында узды. Шәһәребезнең төрле милләт вәкилләре акциядә бик теләп катнаштылар.

5 нче А сыйныфы укучылары һәм сыйныф җитәкчесе Лизия БИКИЕВА.

***

**Шәһәрнең 3нче урта мәктәбендә дә март ае "Мин татарча сөйләшәм" девизы астында үтте.**

5А һәм 7А сыйныфларының рус һәм татар төркемнәрендә укучыларны туган якка мәхәббәт һәм татар теле белән кызыксыну берләштерде. Укучылар татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ләйсән Волкова җитәкчелегендә үткәрелгән акциядә катнаштылар. 7А сыйныфы укучылары җәмәгать урыннарында кешеләр белән аралаштылар. Акциядә катнашучыларга яшел төстәге тасмалар бирделәр, "Мин татарча сөйләшәм" символлы эмблемалар тараттылар. 5А сыйныфының рус телле укучылары татар теле дәресләрендә тупланган белемнәрен төрле әңгәмәләрдә күрсәттеләр. Мәктәптә узган татар теле атналыгында милләтебезнең танылган шәхесләренә багышланган газеталар чыгарылды, ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар үткәрелде. Ләйсән Волкова 7А сыйныфы укучылары белән "Сара Садыйкова – безнең күңелдә" исемле әдәби-музыкаль кичә үткәрде. Анда укучыларны бөек татар композиторының иҗаты белән таныштырды.

Рәсимә ӘХМӘДИЕВА, директор урынбасары

ДИСПАНСЕРЛАШТЫРУ

# Сәламәтлекне кайгыртырга форсат бар

**Быел 8759 нурлатлы диспансерлаштыру узарга тиеш. 2014 елда аны 7922 кеше – 4289 хатын-кыз һәм 3633 ир-ат үткән.**

– Диспансерлаштыруның иң төп бурычларыннан берсе – йогышлы булмаган авыруларны башлангыч стадияләрендә ачыклау, – диде Нурлат район үзәк хастаханәсе поликлиникасы мөдире Вазыйх Гафуров. – Диспансерлаштыру нәтиҗәсендә өч төркем ачыклана: I төркем – сәламәтләр, IIсе – сәламәт диярлекләр, IIIсе дәвалауга мохтаҗ авырулар.

Билгеле булганча, диспансерлаштыру ике этапта уздырыла. Узган ел беренче этаптан соң төрле күрсәткечләр буенча тайпылышлар ачыкланган. Әйтергә кирәк, бигрәк тә артериаль кан басымы күтәрелү еш күзәтелә икән – 1569 кешедә. Шулай ук кайберәүләр, тәгәлрәге, 898 кеше үзләренең каннарындагы холестерин дәрәҗәсе тәртиптә түгел икәнлеген дә белми йөргәннәр, ЭКГ вакытында 479 очракта тайпылышлар табылган. Мондый күрсәткечләр диспансерлаштыру кирәкме, дигән сорауга турыдан-туры җавап бирә дә инде. Чөнки без поликлиникага, гадәттә, авырый башлагач кына барабыз, ә сәламәт халыкны тикшерү авыруларны башлангыч стадиядә ачыкларга һәм вакытында дәваларга мөмкинлек бирә. Мисал өчен, 5 нурлатлы күздәге кан басымнарының әйбәт түгеллеген белми йөргән, 42 очракта маммограф проблемаларны ачыклаган.

– Диспансерлаштыру уздыру 19 кешедә онкологик авыруны ачыкларга булышты, шуларның 19ы – ир-атлар, – диде поликлиника мөдире. – Асылда 1-3 дәрәҗәдәге рак чире ачыкланса, кызганычка каршы, бер очрак инде 4нче дәрәҗәдә иде.

Беренче этап барышында шулай ук анкеталаштыру да үткәрелә. Бу ысул да авыруларны ачыкларга ярдәм итә.

– Анкеталаштыру барышында суммар йөрәк-кан тамырлары рискы ачыкланды, – ди Вазыйх Габдуллович. – Бу риск 39-60 яшьлек ир-атлар һәм хатын-кызларда, 60 яшьлекләргә караганда, аерата югары.

Диспансерлаштыруның икенче этабы өстәмә тикшерү уздырырга мөмкинлек бирә һәм биредә күп төрле инструменталь-лаборатор тикшеренүләр, беренче этапта ачыкланган күрсәткечләр буенча белгечләр каравы үткәрелә. Мисал өчен, узган ел баш миендәге кан әйләнеше бозылуының – 3, инсульт, атеросклероз һ.б.лар куркынычының – 110, ашказаны-эчәк тракты авыруының – 11, яшерен формадагы шикәр диабетының 9, глаукоманың 5 очрагы ачыкланган.

Әгәр дә яшь категорияләре буенча алсак, 2014 елгы диспансерлаштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, 39-60 яшьлек ир-атларда, хатын-кызларга караганда, кан басымы күтәрелү ешрак күзәтелгән: 370 һәм 38 кеше. Ә менә гәүдәнең чамадан тыш авырлыгы шул ук яшьтәге хатын-кызларда күбрәк: 343 һәм 189. Кызганычка каршы, моның белән 60 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар да интегә. Хәер, бу саннарга карап кына хатын-кызларныңмы яки ир-атларныңмы авыруга тизрәк бирешүе турында нәтиҗә чыгарып булмый. Бәлкем, хатын-кызлар сәламәтлекләренә сакчылрак карыйлардыр һәм алар диспансерлаштыруны да активрак уза.

Быелгы диспансерлаштыру башланганга 3 ай узды инде. Анализ күрсәткәнчә, кешеләр сәламәтлекләренә җаваплырак карый башлаганнар. Моны саннар да раслый – бу елның башыннан 2754 кеше диспансерлаштыру узган, үткән елның шул вакытында бу сан 1000нән дә артмаган иде әле. Ә диспансерлаштыруны үз-үзеңне ничек хис итүгә дә карамастан, узарга кирәк.

- Хәтта кеше үзен сау-сәламәт саныса да, еш кына диспансерлаштыру вакытында хроник йогышлы булмаган авырулар ачыклана, һәм аларны башлангыч стадиядә дәвалау нәтиҗәлерәк була, – дип саный Вазыйх Гафуров һәм диспансерлаштыру программасыннан файдаланырга киңәш итә. Район медиклары исә диспансерлаштыруны поликлиникада гына уздырып калмый. Иртәнге 5тә неврологлар, терапевтлар, УЗИ ясаучылар, лаборантлар шәһәрнең эре предприятиеләренә дә чыгалар.







Шул рәвешле, узган елларда алар УТТ, НПБР, НАТ, шикәр заводы һәм башка предприятиеләр хезмәткәрләрен тикшергәннәр. Мондый практика быел да дәвам итә. Ел башыннан табиблар УТТ һәм РУЭСта булырга өлгергәннәр инде.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

## ИГЪТИБАР!

**2015 елда диспансерлаштыруны 1946, 1949, 1952, 1955, 1958 елгылар, яшьләре өч санына бүленүче кешеләр уза ала.**

НИЧЕК ЯШИСЕҢ, СОЛДАТ

# Армия характер чыныктыра

**Күп егетләр өчен армия хезмәте Ватан алдындагы бурычны үтәү генә түгел, характер ныклыгын күрсәтү мөмкинлеге дә. Ата-аналар адресына часть командирларыннан килеп торучы Рәхмәт хатлары да шул хакта сөйли. Күптән түгел Мамыктан Людмила һәм Валерий Кузьминнар гаиләсе дә шундый хат алган.**

"Улыгызны чын ир-егет итеп тәрбияләвегез өчен рәхмәт белдерәбез. Улыгыз үзен бары тик яхшы яктан гына күрсәтә. Ул җаваплы һәм ышанычлы солдат, хәрби хезмәтнең барлык авырлыкларын ныклы уза. Улыгыз хәрби хезмәт барышында тупланган эшлекле сыйфатларны саклап калыр, дип ышанып калабыз.." – әлеге берничә юл да ата-ананың күңеленә якын. Людмила белән Валерийның олы уллары Максим армиягә узган елның маенда китә. Екатеринбургта 61423нче хәрби частьта хезмәт итә. Армиягә киткәнче аграр техникумны автомеханик белгечлеге буенча тәмамлап, шофер таныклыгы алган була. Таныклыгының армия хезмәтендә кирәге чыккан, ул машина йөртергә өйрәтү буенча инструктор.

- Безнең 4 балабыз, икесе Әлмәттә колледжда укый, берсе – мәктәптә, Максим – олы улыбыз. Туган җирдән читкә киткәч тә үзен күрсәтә алуына шатланабыз, улыбыз белән горурланабыз, - ди әнисе Людмила Ноевна. – Бер елдан тагы бер улыбыз армиягә китәчәк. Ул да Максимнан үрнәк алырдыр, дип уйлыбыз.

Максим – максатчан егет, армиягә кадәр дә яхшы укыган, төрле ярышларда катнашкан. Армиядән кайткач исә полициягә эшкә урнашып, Ватанга хезмәтен дәвам итәргә ниятли.

Светлана ИГНАТЬЕВА

Диалог: газета – укучы

## КОМИССИЯ НИ ӨЧЕН АЛЫНА?

**"Бердәм исәп-хисап үзәге квитанцияләрен түләгәндә банклар ни өчен халыктан комиссия ала икән?" Р. Галимова, Нурлат**

- 2012 елның 1 сентябренә кадәр банкларның комиссиясен Торак милекчеләре ширкәтләре һәм Идарәче оешмалар "Бердәм исәп-хисап үзәге" аша үзләре түләп килде, - ди "ЕРЦ" директоры Чулпан Сөләйманова. – ТР Министрлар Кабинетының 2011 елның 19 декабрендәге карары нигезендә, комиссион суммаларны оптимальләштерү һәм түләүләр башкарылганда ачыклык кертү максатларында, 2012 елның 1 сентябреннән комиссияне милекчеләр түли башлады. Комиссия күләмен банк үзе раслый. Бердәм исәп-хисап үзәгендә һәм uslugi.tatar.ru порталында түләгәндә комиссия алынмый.

Зилия ӘКСАНОВА әзерләде




ИРЕК АГА АЛИШЕВ ГАРМУНДА ДА СЫЗДЫРЫП ҖИБӘРДЕ

# Һәркайсы – легендар шәхес

**Узган атнада район мәгариф бүлеге җитәкчесе һәм хезмәткәрләре Бөек Ватан сугышында катнашкан мәгариф ветераннары янында булдылар.**

– Без бүген сугышта катнашкан һәм әлеге авыр елларны кичергән ветеран-педагогларыбызны хөрмәтлибез, - диде район башкарма комитетының мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов.

– Кызганыч, ветераннарыбызның сафы гына сирәгәя бара. Ел башында 5 педагог ветеранybыз булса, бүген алар нибары 3әү калдылар. Аларның һәркайсы – легендар шәхес. 25 апрельдә 100 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтәчәк Нурлатның елъязмачысы Исаак Сандлер, 46 ел гомерен педагогия өлкәсенә багышлаган Аркадий Кержаков, гади укытучыдан директор вазифасына кадәр җиткән Ирек Алишев, яшьләре олы булса да, мәктәп елларын онытмыйлар. Педагоглык эшчәнлеген сугыш елларыннан соң башлаган укытучылар плеядасы бүген дә актив тормыш алып бара. Исаак Сандлер кебек энтузиаст педагог тырышлыгы белән шәһәребездә, генә түгел, районның күп авылларында туган якны өйрәнү музейлары эшли. 1946 елда, сугыштан соң, Нурлатка әнисе һәм сеңлесе янына кайтып төпләнгән Украина егете Исаак Львович заманында кичке мәктәп директоры, аннан озак еллар тимер юл мәктәбендә завуч һәм немец теле укытучысы булып эшли, район газетасында җәмәгать корреспонденты да була.

Төрнәс авылында яшәүче ветеран-укытучы, шул көннәрдә үзенең 91 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтәчәк Аркадий Кержаковның да тормыш юлы һәм хезмәте күпләргә үрнәк булырлык. Дүрт дистә елын укытучылык хезмәтенә багышлаган Ирек Алишев исә бүген дә районның җәмәгать тормышында актив катнашып яши.

– Гомерем буе эштә булдым, - ди Ирек Исхакович. – Сугыштан яраланып кайту белән укыту эшенә тотындым. Лаеклы ялга чыккач, 10 ел гомеремне балта остасы һөнәренә багышладым.

– Район мәгариф учреждениеләрендә ветераннар белән очрашулар, тимурчылык ярдәме даими оештырылып килә, - ди район мәгариф хезмәткәрләре профсоюз оешмасы рәисе Фәридә Сәгыйрова. – Ә бүгенге акциябез ветеран-укытучыларыбызның хәлләрен белешү, аларны хөрмәтләү һәм бүләкләр тапшыру өчен оештырылды.

Зилия ӘКСАНОВА

**МӘГЪЛҮМАТ**

**Бу көннәрдә мәгариф учреждениеләрендә Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан ветераннар белән очрашулар, төрле чаралар үтә.**

"ФРОНТТАН ХАТ" ПРОЕКТЫ

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

Өчпочмаклы солдат хаты булып
Әбиемнең яши үткәне.
Хәтерли ул кош теледәй хатны
Яу кырыннан өзелеп көткәнен.

Яшәү тыны, өмет, сагыну булып
Килгән хатлар, очкан җаваплар.
Газизләре хатын калкан итеп
Ут эченә кергән солдатлар.

Сугыш урлый солдат бабаемны,
Бик көтсә дә әбием кайтканын,
Тик хат күрә толлык ачысының
Кайнар яшьләр булып акканын.

Еллар үтү белән укый-укый
Таушалса да хатның юллары,
Гомер буе ата сүзен тотып
Тәрбияли әбием улларын.

# Истәлеккә калды хатлары

**Ватанны фашист илбасарларыннан сакларга киткән солдатларның сугыштан язган хатлары әле дә туганнарының архивларында саклана.**

Мингәрәй Ибраһимов Яңа Әлмәт авылында яшәүче тормыш иптәше Закирә апага латин хәрефләре белән биш хат язган. Мингәрәй абый хатлар аша авыл, колхоз хәлләре белән кызыксынган. "...Колхоз урып-җыю эшләрен төгәлләдеме, бәрәңге уңышын җыеп алдыгызмы, терлекләр исәнме, кемнәр сугышка алынды, улым Рәшит үсәме?.." дигән юллар бар аның өчпочмаклы хатларында. Бер хатында исә: "...сугыш озак бармас, күрешүләр якынлашыр, без Вологда шәһәре янында..." дигән. Иске Әлмәт авылыннан киткән Җиһанша Җамалетдинов белән бергә хезмәт итәбез, дигән хаты да бар. Мингәрәй абыйның соңгы хаты 1941 елның 21 октябрендә язылган. Ә 1941 елның азагында Закирә апага авылда иң беренчеләрдән булып иренең һәлак булуы турында кара мөһерле хат килеп төшә.

Иске Әлмәт авылында яшәүче Валентина Семанина (Фокеева) өлкән абыйсы Константинның фронттан язган берничә хатын саклый.

Константинның хатыннан өзекләр: "...Әнием һәм Валя, сезгә сәламнәр җибәреп, исәнлек-саулык теләп калам. Әтидән хат алдым, энем Михаилдан хат килгәне юк. Әни, мин әллә исән калам, әллә үләм, шуңа да Валяны укытырга, белем бирергә тырыш. Сәламәтлегем яхшы, фашистларны куып барабыз. Авылда, өйдә хәлләрегез ничек? Күрше Сәләнгеш авылы егете Александр Никитин белән бергә хезмәт итәбез."

Константин соңгы хатын 1943 елның 15 августында яза, һәм шул көнне Калуга өлкәсенең Киров районы Латыши авылында һөҗүм вакытында яралана, икенче пулядан һәлак була. Аның командиры лейтенант Иваненконың Константинның әнисенә юллаган хатында мондый юллар бар: "Сезнең улыгыз сержант Константин һөҗүмгә барганда һәлак булды. Мин яралангач, аны үземнең урынга калдырган идем. Ул яшь булса да, акыллы, абруйлы, ярдәмчел солдат иде. Ватанны саклаучы улыгыз үзен аямыйча сугышты, шундый егет тәрбияләвегез өчен Сезгә рәхмәт."

Яңа Әлмәт авылыннан Харис Гатин да сугыш башлану белән армия хезмәтенә китә. Ул сугыштан исән-сау йөреп кайткач, командиры, капитан Махлычев Харис абыйның әтисенә юллаган характеристика хаты әле дә саклана. Кызганыч, Харис кына якты дөньядан бик иртә, 28 яшендә үк китеп барды.

Җәүдәт ХӘЙРУЛЛИН, Иске Әлмәт авылы.

"Дуслык" почтасыннан

# Игелекле кешеләр бар

Миңа сигезенче дистәмне ваклаган көннәремдә социаль һәм медицина ярдәме сорап төрле органнарга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Хезмәт пенсиямне кабаттан исәпләтү дә Пенсия фондының Нурлат районы идарәсендә ярдәм иттеләр. Яхшы хәбәрне Самарада стационар дәвалану узганда ишеттем. Шикәрчеләр бистәсендәге почта бүлекчәсе начальнигы Тәнзилә Буркаевага мөрәҗәгатем дә игътибарсыз калмады. Һәр кешенең тормышында да шундый игелекле, ярдәмчел кешеләр күбрәк булсын иде, дип телисе килә.

Светлана ӘҮХӘДИЕВА, Нурлат

# "Сугышлар күрергә язмасын!"

Сугыш башланганда, Флюра әбиемнең әнисе – карт әбием Минҗиһан Садыйковага 13 яшь кенә була әле. Ул көнне карт әбием бүгенгедәй хәтерли: "Әти печән чабып арбага тутырды, өстенә палас җәйде, безне утыртты да, Сабантуйга Норлатка алып китте, без бик шатландык. Әти безне карусельдә әйләндерде, тәмле сулар эчертте. Сабантуй башланып та өлгермәде, кинәт халык чабыша, таралыша башлады. Радиодан коточкыч хәбәр ишетелде: "Сугыш, сугыш... Немец сугыш башлаган..." "Сугыш чыккан", дигән хәбәр яшен тизлегедәй бөтен авылга таралды. Алты көн эчендә авылның ир-атларын сугышка алып бетерделәр. Күрше Үрнәк авылында алты бабай, хатын-кызлар, бала-чагалар гына калды", - дип сөйли карт әби. Сугыш чыккан елны кырда икмәк искиткеч уңа. Тик бу икмәкнең барысын да фронтка озаталар. "1942 нче елны җирне сукаларга атлар, чәчү чәчәргә, эшләргә ирләр калмады. Күп эшләр үгез, сыер җигеп, бала-чагалар, хатын-кызлар, карт-корылар тарафыннан башкарылды. Кырларны көрәк белән казыдык, бабайлар тубал белән чәчтеләр. Болай эшләп кенә күп икмәк үстереп булмый шул! Иген уңмый, ә үзәккә үткеч ачлык көчәя генә бара", - дип сүзен дәвам итеп әбием. Ә күзендә кайнар яшь тамчылары җемелди. Ул елларда әбиләребез башына төшкән сынауларны күз алдына китерүе дә кыен. Яшәр, фронтны кирәк-яраклар белән тәэмин итәр өчен аяктан егылырлык булып арыганда да бирешмәгән алар. Карт әбиемнең Минегаян исемле апасы фронтка солдатларга күп бияләйләр, оекбашлар бәйләп, ә әнисе Миңнеруй әби бәрәңге киптереп җибәргән.

Тәүлегенә 4-5әр сәгать кенә йоклап үткәргән көннәр, атналар, еллар озак, бик озакка сузыла шул! 1418 көнгә сузылган бу рәхимсез сугыш күпме авылдашларны, газиз кешеләрне, сөйгән ярларны юк итте. Күпме баланы ятим калдырды. Сугыш беткән көнне дә яхшы хәтерли карт әбием. "Ул көнне Үрнәк күпере янындагы кырда бәрәңге утыртыр өчен җир казый идек. Атка атланган ир кеше килеп сугыш бетүен, җиңү хәбәрен җиткерде. Барыбыз да авылга йөгердек. Урамда бөтен кеше: "Җиңү! Җиңү!"– дип кычкыра. Мәктәптә укулар булмады. Авылда митинг үткәрделәр. Барысы да шат иде. Митингтан соң тынлык урнашты. Бераздан кайсы шатлыктан, кайсы сугыштан кайтмый калган якын кешесен сагынып елады. Минем, Аллага шөкер, Мөнир абыем да, Нургата абыем да яраланып булса да сугыштан исән кайттылар. Тик сугыш күп югалтулар, кайгы-хәсрәтләр, ятимлекләр алып килде шул...". Карт әбиемә хәзер 87 яшь, әмма хәтере яхшы әле аның. "Сугышлар булмасын, балалар сугыш ачысын, ачлык хәсрәтен күрмәсен, дөньялар тыныч булсын," – дип намаз саен дога кыла карт әбием.

Инсаф РӘХМӘТУЛЛИН, Кизләү мәктәбе

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

## “Нурсан”ны сайлыйк!



**Нурлатның парк зонасында урнашкан дәвалану йорты пациентларны ел әйләнәсе кабул итеп, сәламәтләндерү һәм ял хезмәтләре тәкъдим итә.**

“Нурлатлылар бәхетле”. “Нурсан” санаторий-профилакториендә эшләүчеләргә мондый сүзләрне күрше төбәкләрдән җыелган пациентларыннан гына түгел, сәламәтлекләрен ныгыту өчен йөзләгән чакрымнар узып килүчеләрдән дә ишетергә туры килә.

30 елдан артыграк санаторий пациентларны терәк-хәрәкәт аппараты, ашказаны-эчәк тракты, сулыш органнары, сөяк-мускул һәм йөрәк-кан тамырлары системалары авыруларыннан дәвалый.

“Нурсан” санаторий-профилакторие бүген – физиотерапия процедуралары, массажның төрле төрләре, коры тарттыру, солярий, җылылык, ләм белән дәвалау, косметология капсулалары, фитотерапия, дәвалау диеталары һәм физкультурасы, микроклизмалар, сөлек белән дәвалау һәм башкалар ул...

Сез ылыслы, йод һәм бромлы, диңгез һәм скипидар ванналарының сәламәтлеккә могҗизалы тәэсиреннән дә гаҗәеп сихәт алырсыз. Суның башка төрле тәэсирен сез циркуляр һәм сиптерүче душлар һәм Шарко душында булып та тоярсыз. Умыртка баганасы белән проблемагыз бармы? Һичшиксез, “Нурсан”га барырга кирәк!

Берүк вакытта процедураның теләсә нинди төрен бернинди юлламасыз, хастаханәдә санатор-курорт картасы артыннан чиратлар тормыйча да алырга мөмкин – “Нурсан” югары квалификацияле медицина персоналы белән комплектланган. “Нурсан”ның могҗизалы сәламәтләндерү урыны булуына, әлбәттә, матди тәэмин ителеше дә зур йогынты ясый. Барлык уңайлыклары булган, заманча көнкүреш техникалы ике һәм өч урынлы номерлар биредә, ашханәдә биш тапкыр туклану оештырылган, фитобар, бассейн, инфракызыл сауна, бильярд... Болар сезне “Нурсан”да көтеп торган уңайлыкларның бер өлеше генә әле. Чираттагы ялыгызда бирегә килсәгез, сез ял һәм сәламәтлек артыннан һәрчак монда йөриячәксез. Бәяләр дә кәефегезне төшермәс, чөнки алар 2013нче ел дәрәҗәсендә калды бит. “Нурсан” санаторий-профилакториендәге медицина хезмәтләренең төрләре турында җентеклерәк мәгълүматны Интернеттагы www.nursan.su сайтында, шулай ук 2-22-57, 2-36-63 телефоннары буенча алырга була.

Реклама

**КИЛЕШМӘСКӘ МӨМКИН. БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ КИРӘК.**

## ОАО «Сетевая компания» готовится к паводку

Для предупреждения и оперативной ликвидации возможных чрезвычайных ситуаций на объектах электросетевого комплекса РТ в компании создана специальная паводковая комиссия.

В рамках подготовки к периоду активного таяния снега и вскрытия рек ОАО «Сетевая компания» реализует целый ряд мероприятий, обеспечивающих надежную, безаварийную работу оборудования, зданий и сооружений электросетевого комплекса Республики Татарстан.

Особое внимание уделяется контролю за состоянием опор и участков воздушных и кабельных линий электропередачи, проведению обследования трансформаторных подстанций, попадающих в зону возможного затопления. Особое внимание уделяется защите опор ЛЭП, расположенных в пойменных участках, от подмыва оснований и воздействия льда во время ледохода с укреплением откосов земляных сооружений и берегов в местах, подверженных размыву. Проведен анализ возможности обеспечения резервного питания в случае смыва опор в труднодоступных местах. В центре внимания при этом находятся линии электропередачи, обеспечивающие электроснабжение социально-значимых объектов республики.

На время прохождения паводка в ОАО «Сетевая компания» организовано усиленное дежурство персонала подразделений филиалов. Для возможных аварийно-восстановительных и спасательных работ, в рамках подготовки к паводковому периоду, по ОАО «Сетевая компания» сформированы полностью укомплектованные специальной техникой.

Реализация всех противопаводковых мероприятий осуществляется энергетиками в тесном взаимодействии с местными администрациями, Министерством по делам ГОиЧС, гидрометеорологическими службами и другими организациями, обеспечивающими нормальное функционирование инфраструктуры городов и районов Республики Татарстан.

По завершению паводкового сезона в планах энергетиков – осмотры участков воздушных линий электропередач и подстанций для выявления дефектов и устранения повреждений, которые могла нанести «большая вода».

Во время активного таяния снега и вскрытия рек жителям республики, проживающим в зоне возможного подтопления, следует соблюдать особую осторожность вблизи линий электропередачи и трансформаторных подстанций. Энергетики рекомендуют не приближаться к ним ближе 10 метров.

Если ваш дом попал в объявленный район затопления или при подходе воды вплотную к жилым постройкам, лучше всего заранее отключить электроэнергию.

Если вы заметили обрыв провода, опоры ЛЭП накренившиеся вследствие подмыва водой, подтопление трансформаторной подстанции сообщите об этом в диспетчерскую службу Нурлатского района электрических сетей (НРЭС) 2-07-36, 2-04-58, или по бесплатному телефону 8-800-2000-878 «Горячей линии» ОАО «Сетевая компания», в службы МЧС или местным органам власти. В экстремальных ситуациях за помощью обращайтесь: Единая служба спасения 01, 112 - с мобильного, Полиция 02, Скорая помощь 03. Оперативный дежурный Республиканского центра медицины катастроф Министерства здравоохранения РТ: (843) 293-49-95.

Контактные телефоны РЭС нанесены как на опорах, так и на дверях трансформаторных подстанций. Ни в коем случае не приближайтесь к поврежденным энергообъектам.

Такие меры позволят избежать несчастных случаев от поражения электрическим током и обеспечат электробезопасность жителей республики.

*На правах рекламы*

## БЕР ҖИРЛЕК ХӘБӘРЛӘРЕ

### ОЗЫН ГОМЕРЛЕЛӘР

Фома авыл җирлегендә яшәүче сугыш ветераны толы Мәрьям Камалова май аенда үзенең 90 яшьлеген билгеләп үтәчәк. Сугыш елларының авырлыкларын үз җилкәсендә күп татыган әби 6 бала тәрбияләп үстергән. Тагы бер сугыш ветераны толы Минҗиһан Шагапова һәм тыл хезмәтчәне Рауза Гобәйдуллина да 90ның өстендә икән инде.

### ИКЕАЙЛЫККА КУШЫЛДЫЛАР

Авылда санитар-чистарту икеайлыгын узган атна азагында клуб хезмәткәрләре башлап җибәргән. Алар үз территорияләрен һәм юл буйларын тәртипкә китерү белән мәшгуль булган.

### АВЫЛНЫ ЯШЕЛЛӘНДЕРӘЧӘКЛӘР

Фомалылар быел агач утырту республика акциясе кысаларында авыл паркына 100дән артыграк яшь үсенте утыртырга ниятли. Бу эштән авылның бер генә учреждениесе дә читтә калмаячак, авыл халкы да хәленнән килгәнчә ярдәм итәр, диләр авыл җирлеге башкарма комитетында.

### АВЫРСЫНМЫЙЛАР

Фома авылында шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләр, аеруча савым сыерларның баш санын арттыручылар күбәя бара. Мәсәлән, Радик Гайнуллин, Гомәр Хәлиуллин, Эльмира Хәйбуллина, Әсхәт Зәйнуллиннар үз хуҗалыкларында 5әр, Мансур Җәлалетдинов, Илһам Гайсин, Әхәт Мәхмүтов, Җәмил Хәйруллиннар 6шар баш сыер асрый бүгенге көндә. Моннан тыш, хуҗалыкта 4әр баш сыер асраучылар да шактый, ди.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

Мы делаем вашу жизнь прочнее

склад профнастила
Тел.: 8-927-423-72-72
ПРОФНАСТИЛ, ШТАКЕТНИК
МЕТАЛЛОЧЕРЕПИЦА
САЙДИНГ
ДОБОРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ

склад металлопроката
Тел.: 8-927-038-37-37
ПРОФИЛЬНЫЕ ТРУБЫ
ШВЕЛЛЕРА
АРМАТУРА, УГОЛОК

**ТЕПЛИЦЫ от 4 до 12 метров**

**г. Нурлат, ул. Гиматдинова (напротив нефтебазы)**

Реклама

9 апреля в здании типографии (ул. К.Маркса, 19)

**ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА**
**ПЛАЩИ, ВЕТРОВКИ, КУРТКИ ПАЛЬТО**
**РАСПРОДАЖА ЗИМНЕЙ ОДЕЖДЫ**

*Производство Москвы, Белоруссии.*

**КРУПНАЯ ДИСТРИБЬЮТЕРСКАЯ КОМПАНИЯ**
приглашает на работу
**ТОРГОВОГО ПРЕДСТАВИТЕЛЯ,**
проживающего в г. Нурлат.
Опыт активных продаж, наличие личного а/м.
З/п от 35000. ГСМ. сот. связь, корпоративное обучение.
**Тел. (846) 977-90-19, 8-960-811-09-92 г. Самара**
**Резюме на e-mail: suchkova@dalimo.ru**

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

11 АПРЕЛЯ 2015 ГОДА
1. Взрослая, подростковая гинекология.
2. Кардиология, ревматология.
3. Сосудистая хирургия.
4. Неврология.
5. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование), исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.

18 АПРЕЛЯ 2015 ГОДА
1. Гастроэнтерология.
2. Кардиология, ревматология.
3. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
4. Диетология.
5. Андрология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
6. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместра.

19 АПРЕЛЯ 2015 ГОДА
1. Отоларингология.
2. Эндокринология.

*Реклама*

КДЦ предлагает решение проблем мелких вен, сосудистых паутин на ноге. Предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан». Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**